


# Көллият сулышы

№3 26.12.2022

## Яңа ел белән!

*Шигъри мизгелләр* — *3 бит*

*Кулларыннан гөлләр түгелә...* — *6 бит*

*Матурлык нәрсәдә чагыла?* — *8 бит*



7 нче декабрьдә Казан шәһәрендә "Әйдә шаяРТ" КВН Татар лигасы фестивале узды. Арча районы данын безнең көллият студентлары командасы яклады. Алар лаеклы чыгыш ясап, яңа сезонга уздылар.

7 нче декабрьдә КФУда "Милли хәзинә" Идел буе яшьләр фестиваленең гала-концерты үтте. Безнең көллиятнен иҗат коллективлары әлеге чарада актив катнашып, диплом һәм истәлекле бүләкләргә лаек булдылар.





20 нче декабрьдә безнең студентлар "Эшмәкәрлек эшен ничек башлап җибәрергә?.." дигән темага социаль семинарда катнаштылар. Эшмәкәр Михаил Кузнецов студентларга үз эшләрен үстерү юллары турында сөйләде.

*Редколлегия:*
*Рузилә Каюмова, Ангелина Беспятых, Азалия Шихабиева, Гөлия Шиһабеддинова, Камилә Халикова, Зилия Шәфигуллина*

## Яшьлек сукмагыннан – бриллиант туйга



Кешенең гомер агышын бизмәннәргә салып үлчәп булмый. Аның авырлыгын һәм җиңеллеген адәм баласы үзе генә белә. Бу сүзләр 60 ел пар канат булып, иңне-иңгә куеп гомер итүче Илдус Габдрахман улы һәм Флера Гомәр кызы турында.

Бриллиант туй – 60 ел уртак язмыш, уртак гомер. Аны алмаз туй дип тә атыйлар. 60 ел бергә бәхетле гомер итү – иң кыйммәтле, затлы асылташ – бриллиантка, алмазга тиң гомер.

2 нче декабрь көнне Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең “Әлифба” музеенда Илдус Габдрахман улы һәм Флера Гомәр кызының 60 ел бергә гомер итүләре уңаеннан “Яшьлек сукмагыннан – бриллиант туйга” дип аталган әдәби кичә үткәрелде. Чараны көллиятебез директоры Гарипова Гөлнара Фидаил кызы ачып җибәрде. Ул шәхсән үзе һәм коллектив исеменнән матур теләкләрен җиткерде. Шулай ук алар белән бергә дус-тату эшләгән хезмәттәшләре – ветеран укытучыларыбыз да эшләү дәверендә булган җылы мизгелләрне кабаттан яңарттылар. Кичә бер сулышта узды.

Шундый кешеләр була – алар белән сөйләшсәң, киңәшсәң, үзеңне дөньяга яңадан туган кебек хис итәсең. Иртәгесе көн өчен ышанычың арта, өмет чаткысы кабына. Аларның хак сүзләре, мәгънәле фикерләре, сине үзе белән тигез күреп, ихластан сөйләшүләре тормышка карашыңны үзгәртә, яшәргә көч бирә. Бу сүзләр нәкъ менә Илдус абый һәм Флера апа турында!

*Рәхмәт Сезгә*
*Кешелекле булганыгыз өчен,*
*Кирәк чакта*
*Ярдәм кулы сузганыгыз өчен.*
*Беркайчан да кайгы-хәсрәт күрмәгез,*
*Шатлыктан башканы Сез белмәгез.*
*Сау-сәламәт булыгыз,*
*Тигезлектә, татулыкта торыгыз.*



**Гөлия Шиһабеддинова**

# *Новогоднее вдохновение…*

## *Новогодняя пора*

Пролетает год за годом,
Снег парит над головой,
Праздник назван Новым годом,
Суета стоит кругом.

Праздник яркий, праздник пёстрый,
Слоем снега покрыт толстым.
Новый год - это праздник очень особый,
По нему не написано разных пособий.

Ведь это праздник надежды и грёз.
Порой, не обходиться без добрых слёз.
Все тревоги свои ты сейчас же отбрось.
Посмотри, сколь людей уже собралось.

Папа смотрит телевизор,
Мама украшает стол,
Ребёнок сильно ждёт сюрприза
И хочет разорвать танцпол.

Подарки, ёлка, мандарины –
Всё вокруг прекрасно.
Гирлянды как огромные лавины
Горят на ёлке ярко красно.

Дед мороз спешит в дома –
Времени в обрез.
На санях сквозь все кома,
Чтоб в камин пролезть.

Куранты ударят звуком мечты
В то светлое с нежностью теплоты.
Смотри! Огни салюта, они так милы –
Яркие краски среди полумглы.

Время идёт, пора году смениться.
2023-ий пора возводиться.
И нам всем в него с головой погрузиться
И дарить миру только добро…

**Ангелина Беспятых, 111 группа**

***Каләм тибрәтер вакыт...***



## ***Яңа елга–яңа хыяллар.***

Менә бит нинди хикмәт! Көн артыннан көн, ай артыннан ай, ел артыннан ел үтә дә китә. Бүгенгедәй истә бит әле узган елга планнар корганым. Планнар дигәндә, алар күп тә түгел. Минем бит, шушы елларда, төп хыялым – Арча педагогия көллиятендә төпле гыйлем алу. Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте – танылган шәхесләр тәрбияләп чыгаруы белән дан тоткан урта һөнәри белем бирү уку йорты.

Арча педагогия көллияте – ул бренд. Чыннан да, көллияткә бик яхшы әзерлекле кадрлар тупланган. Алар үзләре югары әхлаклы, ярдәмчел, кешелекле. Минем дә аларның шушы сыйфатларын үземә сеңдереп, киләчәктә, үз тәҗрибәмдә кулланасым килә. Гыйлем бирү юлында тырышу үзе зур бәхет дип саныйм. Бер галим: “Гыйлем иясе, яки гыйлем алучы, яки гыйлем  тыңлаучы бул”, – дигән...

Спорт белән шөгыльләнүем укуга зыян китерми. Көллият данын, Татарстан Республикасы, Рәсәй данын саклау –мәртәбәле дәрәҗә. Активлык, көчле булу укытучы эшендә бик кирәк дип саныйм. Һәм “Спорт остазы” исеме булганда, аны алырга тырышырга кирәктер.

Хыяллану, алдан планнар кору, алдыңа югары максатлар – кую бик кирәкле эш. Чөнки максат булганда гына, нәтиҗә була. Нәтиҗәгә карап, хаталарны төзәтәсең, файдалы якларын күрәсең. Шуның өчен дә хыял-планнарны язып кую тиешле. Язган әйбергә һәрвакыт мөрәҗәгать итеп була. Елга бер мәртәбә отчет ясап, казаныш-кимчелекләрне, киләсе елга беренчел максатларны барлап, яңа елга максат-бурычларны планлаштыру һәрбер кешегә файдалы булыр дип уйлыйм.

Вакыт турында искә алсак, вакыт – ул бик күп көчләр түгеп тә, кире кайтарып булмый торган олуг нигъмәттер. Без теләсәк тә, теләмәсәк тә, үз көенә чаба да чаба. Элекке заманда, 1000 ел яшәгән бер галимнән гомереӊ ничек үтте, дип сораганнар. Галим кеше: “Бер ишектән кереп, икенче ишектән чыккан кебек булды”, – дигән.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: “Хыяллаңыйк, матур планнар корып, аларны тормышка ашырырга ашыгыйк. Гыйлемле, югары әхлак ияләре булып көллият укытучыларын, әти-әниләребезне сөендерик. Башка кешеләрнең уңышларына сөенергә өйрәник!”

**Шәфигуллина Зилия, 231 нче төркем**

## *Яңа елга – якты теләк...*

***2022 нче ел минем өчен яңалыкларга, табышларга бик бай булды. Дөньядагы хәлләргә карамастан, укырга һәм камилләшергә мөмкинлекләр юк түгел иде. Укуыма үрелеп иҗатым да үсте, әдәби чаралардан, бәйгеләрдән дә читтә калмадым. Бер урында тапталмау, гел алга бару – үзе бер бәхет. Бу – үз-үземне үстерүдә зур адымнар дип саныйм. Көллиятем дә шул адымнарны ясарга, үземне бөтенләй башка яктан ачарга ярдәм итте..***

***Үтеп барган елда хәтирәләр, шатлыклар күп булуга карамастан, Яңа елның яңа максатлары, уйлары белән килүе алга таба зур этәргечем булып тора. Һәрбер кешенең дә Яңа елны чиксез ярату, зур өметләр, сүнмәс хыял белән каршы алуын телим. 2023 нче ел бары куанычлар гына алып килсен!***

**Камилә Халикова, 213 нче төркем**

# *Кулларыннан гөлләр түгелә...*

## Дарья Тимофеева: “Минем өчен бу бик зур тәҗрибә булды...”



**Даша, ничек син кул эше белән шөгыльләнә башладың, шул хакта тулырак сөйлә әле?**

– Мин кул эшенә якынча 7 яшьтә тартыла башладым. Мине апам барысына да өйрәтте. Аның ничек үз куллары белән төрле-төрле матур әйберләр ясаганын сокланып карап тора идем. Тора-бара мин аңа ярдәм итә башладым һәм үзем дә кул эшенә бик остарып киттем.

**Кул эшенең нинди төрләре белән шөгыльләнәсең?**



– Дөресен генә әйткәндә, кул эшенең бөтен юнәлешләрендә дә үземне сынап карадым: рәсем ясаудан башлап сәйлән белән чигүгә кадәр. Бу өлкәләрдә мин инде шактый тәҗрибә туплара өлгердем.

**Ләкин, шулай да кайсы юнәлеш сиңа күбрәк ошый?**

–Хәзерге вакытта бәйләү минем күңелемә күбрәк ята. Төрле йомшак уенчыклар бәйләү бигрәк тә ошый миңа.

**Кул эше белән шөгыльләнә башлаган мәлләрдә син иң беренче нинди конкурсларда һәм күргәзмәләрдә катнаштың?**

–Баштагы мәлләрдә мин күбесенчә мәктәптә үткәрелә торган ярышларда һәм күргәзмәләрдә катнаша идем. Мисал өчен, шул ук әниләр көненә багышланган бәйгеләр. Соңрак инде район буенча үткәрелә торган төрле чараларда да әкренләп катнаша башладым.



**Синең әлеге шөгыленә әти-әниләрең һәм дусларың ничек карый?**

–Дусларыма минем әлеге кызыксынуым бөтенләй кызык түгел, ә әнием исә мине бик үк җитди булмаган әйбер белән шөгыльләнәм дип саный. Ләкин шуңа карамастан, ул

минем төрледән-төрле матур кул эшләрем белән соклана һәм горурлана, өебезгә кунаклар килгән саен, аларга минем иҗат җимешләремне күрсәтә.



**Иҗатыңны үстерү максаты белән синең тагын нинди конкурсларда катнашканың булды?**

– Мәктәптәге төрле ярышлар һм район күләмендәге олимпиадалардан соң көллияттә дә иҗади эшемне актив рәвештә дәвам итәргә мөмкинлек булды. Менә күптән түгел генә республикакүләм конкурс-күргәзмәдә катнашырга да туры килде.

**Әлеге конкурс турында тулырак сөйлә әле?**

–Әлеге бәйге 2 этаптан тора иде. Беренче этапта без иҗади җитәкчем белән бергәләп славян халыклары арасында популяр булган саклагыч-курчак ясау буенча мастер-класс күрсәтеп, аны видео форматында әзерләп җибәрдек. Шуннан соң мин 2 нче этапка үздым. Ул Әлмәт шәһәренең политехник техникумында үтте. Анда мин шул ук кул эшемне эшләү буенча мастер-класс күрсәттем һәм жюри әгъзаларына үземнең иҗади эшләремнән торган күргәзмәне тәкъдим иттем.





**Конкурс синең күңелеңдә нинди тәэсирләр калдырды?**

– Әлеге бәйгедә мин моңарчы бер дә күрмәгән, үзем өчен өр-яңа шәһәр белән таныштым, күп кенә матур урыннарны күрдем. Гомумән, конкурс кысаларында үткәрелгән әлеге кечкенә генә сәяхәт миңа бик ошады һәм күңелемә кереп калды. Шулай ук бәйгедәге башка студентларның төрледән-төрле иҗади эшләре дә минем игътибарымны җәлеп итте. Минем өчен бу бик зур тәҗрибә булды. Ләкин шулай да, икенче урын гына яулавым өчен миңа әзрәк аяныч булды дисәм дә ялгыш булмас. Шуңа да карамастан, күңелемне төшермәскә тырышам, чөнки әлеге иҗади сынау миңа үзем өстендә эшләп, яңадан-яңа үрләр яуларга һәм киләчәктә тагын да зуррарк җиңүләргә ирешергә бер этәргеч булды.

***Әңгәмәдәш – Ангелина Беспятых, 111 нче төркем***

***Татарчага тәрҗемә итүче – Рузилә Каюмова***


# *Матурлыкны күрә белә эчкерсез күңел генә...*









***Фотоколлажның авторы – Азалия Шихабиева, 112 нче төркем***